**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об объектах культурного наследия в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
28 июня 2016 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 1 апреля 2005 года № 60-ЗРТ «Об объектах культурного наследия в Республике Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 2 июля 2015 года № 51-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2005, № 4 (I часть); 2015, № 7 (I часть), № 10 (I часть) следующие изменения:

1) в части 2 статьи 4:
а) пункт 4 дополнить словами «, требований к градостроительным регламентам в указанных границах»;
б) дополнить пунктом $9^2$ следующего содержания:
«$9^2$) принятие в соответствии со статьей $34^1$ Федерального закона решения, предусматривающего установление границ защитной зоны объекта культурного наследия на расстоянии, отличном от расстояний, предусмотренных пунктами 3 и 4 статьи $34^1$ Федерального закона;»;

2) часть 1 статьи 11 дополнить абзацем следующего содержания:
«В случае обнаружения места захоронения жертв массовых репрессий заявление в орган охраны объектов культурного наследия Республики Татарстан направляет орган местного самоуправления.»;

3) в статье 16:
а) наименование статьи изложить в следующей редакции:
«Статья 16. **Порядок утверждения перечня исторических поселений регионального значения, предмета охраны исторического поселения регионального значения, границ территории исторического поселения**

**регионального значения, требований к градостроительным регламентам в указанных границах»;**

б) в части 11 слова «и границы территории исторического поселения регионального значения» заменить словами «, границы территории исторического поселения регионального значения, требования к градостроительным регламентам в указанных границах»;

в) дополнить частью $11^1$ следующего содержания:

«$11^1$. Перечень исторических поселений регионального значения, предмет охраны исторического поселения регионального значения, границы территории исторического поселения регионального значения, требования к градостроительным регламентам в указанных границах, утвержденные в установленном порядке, не позднее пяти рабочих дней со дня принятия решения об их утверждении направляются в орган местного самоуправления муниципального образования, в границах которого расположено историческое поселение регионального значения.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования, за исключением подпункта «б» пункта 1 статьи 1, который вступает в силу с 3 октября 2016 года.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань,Кремль
6 июля 2016 года
№ 52-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында” 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2015 елның 2 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 2 өлешендә:

а) 4 пунктка “территориясе чикләрен” сүзләреннән соң “, күрсәтелгән чикләрдә шәһәр төзелеше регламентларына таләпләрне” сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $9^2$ пункт өстәргә:

“$9^2$) Федераль законның $34^1$ статьясы нигезендә мәдәни мирас объектын саклау зонасы чикләрен Федераль законның $34^1$ статьясындагы 3 һәм 4 пунктларында каралган ераклыклардан үзгә ераклыкта билгеләү каралган карар кабул итү;”;

2) 11 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“Массакүләм репрессияләр корбаннары күмелгән урыннар табылган очракта, Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органына гариза җирле үзидарә органы тарафыннан җибәрелә.”;

3) 16 статьяда:

а) статьяның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“16 статья. **Региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр исемлеген, региональ әһәмияттәге тарихи җирлекнең саклау предметын, региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрен, күрсәтелгән чикләрдә шәһәр төзелеше регламентларына таләпләрне раслау тәртибе**”;

б) 11 өлештә "һәм региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләре" сүзләрен ", региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләре, күрсәтелгән чикләрдә шәһәр төзелеше регламентларына таләпләр" сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле $11^1$ өлеш өстәргә:

"$11^1$. Билгеләнгән тәртиптә расланган региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр исемлеге, региональ әһәмияттәге тарихи җирлекнең саклау предметы, региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләре, күрсәтелгән чикләрдә шәһәр төзелеше регламентларына таләпләр, аларны раслау турында карар кабул ителгән көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, чикләрендә региональ әһәмияттәге тарихи җирлек урнашкан муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органына җибәрелә.".

**2 статья**

Әлеге Закон, 2016 елның 3 октябреннән үз көченә керә торган 1 статьяның 1 пунктындагы "б" пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН *
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2016 елның 6 июле
№ 52-ТРЗ